РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 27 мае Кукмара ш. № 122

Кукмара муниципаль районы Советының 2011 елның 28 ноябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәне «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирә:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2011 елның 28 ноябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә (Кукмара муниципаль район Советының 2014 елның 14 мартындагы 05 номерлы, 2014 елның 23 маендагы 26 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I.1. 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 нчы өлешне өстәргә:

«6. Контроль-хисап палатасы ведомство бүләкләре һәм мактау билгеләрен гамәлгә куя, әлеге бүләкләр һәм билгеләр турында нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен раслый ала.»;

I.2. 3 статьяга «бәйсезлек» сүзеннән соң «ачыклык» сүзен өстәргә;

I.3. 4 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Контроль-хисап палатасының штат саны, законнар белән йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, Контроль-хисап палатасының оештыру һәм функциональ бәйсезлеген тәэмин итү зарурилыгын исәпкә алып, Контроль-хисап палатасы рәисе тәкъдиме буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының хокукый акты белән билгеләнә.»;

I.4. 5 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, әлеге Нигезләмәнең 6 статьясында билгеләнгән квалификация таләпләренә Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатларның туры килү-килмәве турында бәяләмә сорап, Татарстан Республикасы Хисап палатасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

1.5. 6 статьяда:

а) 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белеме булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанслар, юриспруденция өлкәсендә биш елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән, Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең Контроль-хисап органнары тарафыннан контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына карата Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган гомуми таләпләрне белү.»;

б) 2 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил гражданлыгы (подданство) йә яшәү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булуы;»;

в) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 5 нче пунктны өстәргә:

5) 5) әлеге статьяның 3 өлешендә каралган нигезләрнең булуы.»;

г) 3 өлештә «һәм ир белән хатынның балалары» сүзләрен «, ир белән хатынның балалары һәм балаларның ир белән хатыны» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 7 статьяның 5 өлешендә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил гражданлыгы (подданство) йә яшәү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булуы;»

б) түбәндәге эчтәлекле 8 нче пунктны өстәргә:

«8) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны үтәмәү»;

1.7. 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Контроль-хисап палатасы вәкаләтләре

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге төп вәкаләтләрне башкара:

1) җирле бюджет акчаларын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка чараларны куллануның законлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза, аның күрсәткечләренең нигезле булуын тикшерү һәм анализлау;

3) җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милек формалаштыру, мондый милек белән идарә итү һәм аның белән эш итү нәтиҗәлелеген бәяләү, мондый милек формалаштыру, мондый милек белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тоту (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукларны да кертеп);

6) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр һәм поручительлекләр бирүнең законлылыгын яисә юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан җирле бюджет һәм муниципаль милектәге мөлкәт акчалары исәбеннән башкарыла торган алыш-бирешләр буенча башка ысуллар белән йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә муниципаль хокукый актлар проектларына экспертиза, җирле бюджет керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына) экспертиза ясау;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында җирле бюджетның үтәлешен оештыруны оператив анализлауны һәм тикшерүне үткәрү, җирле бюджет үтәлеше барышы, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитика чаралары нәтиҗәләре турында квартал саен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына һәм муниципаль берәмлек башлыгына мәгълүмат тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурыч торышына контрольне гамәлгә ашыру;

11) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеше максатларына ирешүнең тормышка ашырылуын, хәвеф-хәтәрләрен һәм муниципаль берәмлекне стратегик планлаштыру документларында каралган муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү максатларына ирешү нәтиҗәләрен Контроль-хисап палатасы компетенциясе кысаларында бәяләү;

12) коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу;

13) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендә башка вәкаләтләр.

2. Контроль-хисап палатасы Кукмара муниципаль районына керә торган җирлекләр бюджетларына кергән Кукмара муниципаль районы бюджеты акчаларын куллануның законлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә контрольлек итә.

3. Тышкы муниципаль финанс контроле Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла:

1) җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль унитар предприятиеләргә карата, шулай ук, әгәр алар муниципаль берәмлек милкендә булган мөлкәтне куллансалар, башка оешмаларга карата;

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракта, башка затларга карата.»;

1.8. 10 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган Гомуми таләпләр нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан раслана.

1.9. 11 статьяның 3 өлешендә «һәм запрослар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.10. 15 статьяда:

в) түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлешен өстәргә:

«2.1. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләре Контроль-хисап органнарының контроль чараларында катнашучы тиешле вазыйфаи затларын белешмә хокукый системаларга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә керү мөмкинлеге булган эш урыны белән тәэмин итәргә бурычлы.»

б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлешен өстәргә:

4.1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга бурычлы»;

1.11. 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 нчы өлешне өстәргә:

«9. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда, Контроль-хисап палатасына аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалану рөхсәт ителә.»;

1.12. 17 статьяда:

а) 1 өлештә «аларны карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет һәм башка» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә «күрсәтмәне алган көннән бер ай эчендә» сүзләрен «күрсәтмәдә бирелгән вакытта яки, әгәр вакыты күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән 30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга, «карау» сүзен «үтәү» сүзенә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлешен өстәргә:

«3.1. Күрсәтмәне үтәү вакыты Контроль-хисап Палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин күп дигәндә бер тапкыр.»

г) 4 өлештә «аларны булдырмау һәм кисәтү» сүзләреннән соң «контроль-хисап органнары күрсәтмәләрен үтәмәү,» сүзләрен өстәргә;

д) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтмәне үтәү срогы Контроль-хисап Палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.»;

е) 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Хокук саклау органнары Контроль-хисап палатасы тарафыннан тапшырылган материаллар буенча тикшерү барышы һәм кабул ителгән карарлар турында Контроль-хисап палатасына мәгълүмат бирергә тиеш.»;

1.13. 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсен яисә боерыгын үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.»;

1.14. 19 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Контроль-хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә контроль һәм эксперт-аналитика

чараларын үткәрүдә катнашуга контроль, хокук саклау һәм башка органнарны һәм аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамә нигезендә аудитор, фәнни-тикшеренү, эксперт һәм башка учреждениеләрне һәм оешмаларны, аерым белгечләрне, экспертларны, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.»;

1.15. 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларын матди һәм социаль тәэмин итү

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына акчалата түләү (бүләкләү), ел саен түләнә торган отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, муниципаль берәмлек бюджеты хисабына тормыш һәм сәламәтлек өчен мәҗбүри дәүләт иминиләштерүе, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэминатның башка чаралары гарантияләнә.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башлыгы С.Д. Димитриев